Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.10.2023 ел Менделеевск ш. №613

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тын таулар» торак массивы» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2018 елның 2 августындагы 60 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 20 ноябрендә 16 сәгатьтә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының административ бинасында түбәндәге адрес буенча: Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт, актлар залында «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тын таулар» торак массивы» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проекты буенча халык тыңлаулары уздырырга

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Искаков А.Ф. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе;

Готин Ю.А.- «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы;

Хәбиров Р.З. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы хезмәте архитекторы;

Антоновская Н.И. - Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча).

3.2023 елның 18 октябреннән 2023 елның 20 ноябренә кадәр «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тын таулар» торак массивы» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты материаллары экспозициясен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автономияле учреждениесенең баш архитеторы хезмәтендә: Менделеевск ш., Фомин ур., д19 йорт (5 кат) оештырырга

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 432650, Татарстан Республикасы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт («Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы исеменә).

5.Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга http://Mendeleevsk.tatar.ru.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы Р.З. Хәбировка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелде:

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

ТР Менделеевск МР
«ИИҮИ» МАУнең баш архитектор
хезмәте архитекторы Р.З.Хәбиров